ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

04 июль 2025ел

№ 4906

Башкарма комитетның 2022 елның 9 августындагы 4005 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнаштыру өчен төзелешкә рөхсәт таләп ителми торган мондый корылмалар һәм (яки) конструкцияләр чикләрендә велосипедларны, индивидуаль мобильлек чараларын, төрле спорт инвентарен куюны һәм (яки) саклауны (тотуны) оештыру өчен билгеләнгән вакытлыча корылмаларны һәм (яки) вакытлыча конструкцияләрне урнаштыру схемасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт яки муниципаль милектәге җирләрдә яки җир участокларында, җир участоклары бирмичә һәм сервитутлар, җәмәгать сервитуты билгеләмичә, төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган объектларны урнаштыру тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2015 елның 5 июнендәге 416 номерлы Карарының 3 пункты, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнаштыру өчен төзелешкә рөхсәт таләп ителми торган мондый корылмалар һәм (яки) конструкцияләр чикләрендә велосипедларны, индивидуаль мобильлек чараларын, төрле спорт инвентарен куюны һәм (яки) саклауны (тотуны) оештыру өчен билгеләнгән вакытлыча корылмаларны һәм (яки) вакытлыча конструкцияләрне урнаштыру схемасына кертү комиссиясе утырышының 2025 елның 11 июнендәге 3 номерлы беркетмәсе нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2022 елның 9 августындагы 4005 номерлы Карары белән (Башкарма комитетның 2023 елның 16 февралендәге 1023 номерлы, 2023 елның 3 апрелендәге 2601 номерлы, 2023 елның 7 июлендәге 5942 номерлы, 2024 елның 6 маендагы 2829 номерлы, 2024 елның 18 октябрендәге 6870 номерлы, 2025 елның 14 мартындагы 1981 номерлы Карарлары редакциясендә) расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнаштыру өчен

төзелешкә рөхсәт таләп ителми торган мондый корылмалар һәм (яки) конструкцияләр чикләрендә велосипедларны, индивидуаль мобильлек чараларын, төрле спорт инвентарен куюны һәм (яки) саклауны (тотуны) оештыру өчен билгеләнгән вакытлыча корылмаларны һәм (яки) вакытлыча конструкцияләрне урнаштыру схемасына, кушымтада каралганча 22 пункт өстәп, үзгәрешләр кертергә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның Үзәк районы хакимияте Башлыгы Ф.Ф. Хәбибуллинга, Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2025 елның 4 июлендәге
4906 номерлы карарына
кушымта

| № т/б | Объектның урнашу урыны | Объектның мәйданы, кв.м | Объектның төре | Объектның урнашу урыны координаталары |
|---|---|---|---|---|
| Үзәк районы | | | | |
| 22 | Ф. Табеев исемендәге яр буе | 18 | Мондый корылмалар һәм (яки) конструкцияләр чикләрендә велосипедларны, индивидуаль мобильлек чараларын, төрле спорт инвентарен куюны һәм (яки) саклауны (тотуны) оештыру өчен билгеләнгән вакытлыча корылма һәм (яки) вакытлыча конструкция | 469826,52 2320622,38<br>469828,09 2320624,95<br>469822,95 2320628,06<br>469821,40 2320625,49 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ «ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН» УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Н.И. Галиева